СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19.11.2019 Әгерҗе шәһәре № 41-6

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Физик культура һәм спортны үстерү һәм аңа ярдәм итү фонды» коммерцияле булмаган оешмасын гамәлгә куючылар составыннан чыгуы турында

«Коммерциясез оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 3 пунктының беренче абзацы, «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 2.2 пункты, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының 2016 ел 8 декабрендәге 11-141929/16 номерлы хаты, «Юридик затларны, шәхси эшкуарларны һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларын дәүләт теркәвенә алганда теркәү органына тапшырыла торган документларны рәсмиләштерү формаларын һәм таләпләрен раслау турында» 25.01.2012 ел, № ММВ-7-6/25@ Россия Федераль салым хезмәте боерыгы (Россия Юстиция министрлыгында 14.05.2012, № 24139 теркәлгән) нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2011 ел 12 апрелендәге 6-5 номерлы “Физик культура һәм спортны үстерү һәм аңа ярдәм итү фонды” коммерцияле булмаган оешмасын гамәлгә кую турында карары, “Физик культура һәм спортны үстерү һәм аңа ярдәм итү фонды” коммерцияле булмаган оешмасы Уставы һәм 12.11.2019 ел, № ЮЭ9965-19-112834497 номерлы “Физик культура һәм спортны үстерү һәм аңа ярдәм итү фонды” коммерцияле булмаган оешма турында белешмәләр тупланган юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (ИНН 1601007482, ОГРН 1111600001996) нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Физик культура һәм спортны үстерү һәм аңа ярдәм итү фонды» коммерцияле булмаган оешмасын гамәлгә куючылар составыннан Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советын ирекле нигездә төшереп калдырырга.

2. «Физик культура һәм спортны үстерү һәм аңа ярдәм итү фонды» коммерцияле булмаган оешмасын гамәлгә куючылар составыннан Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Советының чыгуына бәйле рәвештә, дәүләт теркәвенә алу өчен, үзгәрешләр кертү турында гамәлгә кую документларын Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru/rus/index.htm веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы,
Совет Рәисе

В. В. МАКАРОВ